| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**27.10.2021** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2685** |
|---|---|---|

2022 елга Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларына норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 21 декабрендәге 1879 номерлы карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Кушымта итеп бирелгән Зеленодольск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга 2022 елга норматив чыгымнарны расларга (1 нче кушымта).

2. Түбәндәгеләр тарафыннан расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә, «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МУ мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә:

- «2022 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында»» 2021 елның 25 сентябрендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы ( 2 нче кушымта);
- әлеге карарның 1 пункты.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы

муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Р. Ганиев

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2021 нче
елның 27 октябрендәге
2685 номерлы карарына карата
1 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат- мәктәпләрдә тәрбияләнүчеләрне тотуга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль урнашу | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы Интернат | шәһәр җире | 97391 |
| | авыл җире | 98753 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җире | 143889 |
| | авыл җире | 148363 |